**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**ГОРОДА ЛАИШЕВО**

422610 г.Лаишево,
ул. Коммунальная, д.3
тел: 8-(84378) -2-50-62
факс: 8-(84378) -2-50-62

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЛАЕШ ШӘҺӘРЕ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

422610 Лаеш ш.,
Коммунальная ур., 3 нче йорт
тел: 8-(84378) -2-50-62
факс: 8-(84378) -2-50-62

**2026 елның 25 марты** **90 /исх. номер**

# КАРАР

**Татарстан Республикасы, Лаеш муниципаль районы, Лаеш шәһәре адресы буенча урнашкан 16:24:170109:55 кадастр номерлы җир участогы территориясен межалау проектын раслау мәсьәләсе буенча ачык тыңлаулар башлануы турында хәбәр**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Лаеш шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставы, Лаеш муниципаль районы Советының 2018 елның 12 ноябрендәге 61-РС номерлы карары белән расланган (Лаеш муниципаль районы Советының 2019 елның 11 декабрендәге 96-РС номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә ачык тыңлаулар (җәмәгать фикер алышулары) оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы Нигезләмә, Башкарма комитетның 2026 елның 24 мартындагы 8 нче номерлы «Татарстан Республикасы, Лаеш муниципаль районы, Лаеш шәһәре адресы буенча урнашкан, 16:24:170109:55 кадастр номерлы җир участогы территориясенең межалау проектын раслау мәсьәләсе буенча ачык тыңлаулар билгеләү турында»гы карары нигезендә, кешенең уңайлы яшәү шартларына булган хокукларын, капиталь төзелеш объектлары хокук ияләренең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен саклау максатыннан, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Лаеш шәһәре Башкарма комитеты хәбәр итә:

2026 елның 25 мартыннан 21 апреленә кадәр Татарстан Республикасы, Лаеш муниципаль районы, Лаеш шәһәре адресы буенча урнашкан, 16:24:170109:55 кадастр номерлы җир участогы территориясенең межалау проектын раслау мәсьәләсе буенча ачык тыңлаулар үткәрү турында.

1.Мәгълүмат материаллары:

Татарстан Республикасы, Лаеш муниципаль районы, Лаеш шәһәре адресы буенча урнашкан, 16:24:170109:55 кадастр номерлы җир участогы территориясенең межалау проекты.

2.Татарстан Республикасы, Лаеш муниципаль районы, Лаеш шәһәре адресы буенча урнашкан, 16:24:170109:55 кадастр номерлы җир участогы территориясенең межалау проектын раслау мәсьәләсе буенча ачык тыңлауларда катнашучылар дип түбәндәгеләр таныла: «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Лаеш шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендә даими яшәүче гражданнар, җирлек чикләрендә урнашкан

капиталь төзелеш объектларына хокук ияләре, шулай ук әлеге капиталь төзелеш объектының өлеше булган биналарның (помещениеләрнең) хокук ияләре.

3.Татарстан Республикасы, Лаеш муниципаль районы, Лаеш шәһәре адресы буенча урнашкан 16:24:170109:55 кадастр номерлы җир участогы территориясен межалау проекты экспозициясе Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында (веб-адресы: https://laishevo.tatarstan.ru/publichnoe-obsuzhdenie-5676969.htm) «ПУБЛИЧНОЕ ОБСУЖДЕНИЕ» («АЧЫК ФИКЕР АЛЫШУ») вкладкасында, шулай ук Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Лаеш шәһәре Башкарма комитеты бинасында (адресы: Татарстан Республикасы, Лаеш шәһәре, Коммунальная урамы, 3 нче йорт, киңәшмәләр залында) ачылачак.

Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында (веб-адресы: https://laishevo.tatarstan.ru/publichnoe-obsuzhdenie-5676969.htm) урнаштырылган проект материаллары белән экспозициянең бөтен вакыты дәвамында тәүлек буе танышырга мөмкин. Лаеш шәһәре Башкарма комитеты бинасында проект белән 2026 елның 3 мартыннан 16 мартына кадәр 13:00 сәгатьтән 17:00 сәгатькә кадәр танышырга була.

Ачык тыңлауларда катнашучылар җыелышы түбәндәге вакытта уздырылачак:

Лаеш шәһәрендә 2026 елның 17 апрелендә 15:00 сәгатьтә түбәндәге адрес буенча: Лаеш шәһәре, Коммунальная урамы, 3 нче йорт – Лаеш шәһәре Башкарма комитеты бинасы;

3 нче пунктта күрсәтелгән чор эчендә ачык тыңлауларда катнашучыларның Татарстан Республикасы, Лаеш муниципаль районы, Лаеш шәһәре адресы буенча урнашкан 16:24:170109:55 кадастр номерлы җир участогы территориясенең межалау проектына кагылышлы тәкъдимнәрен һәм искәрмәләрен түбәндәге тәртиптә кертү хокукы бар:

ачык тыңлауларны оештыручы адресына язма рәвештә түбәндәге адрес буенча: Татарстан Республикасы, Лаеш шәһәре, Коммунальная урамы, 3 нче йорт;

проект экспозициясенә килүчеләрне исәпкә алу китабында (журналында) язу калдыру аша түбәндәге адрес буенча: Татарстан Республикасы, Лаеш шәһәре, Коммунальная урамы, 3 нче йорт.

Шулай ук Татарстан Республикасы, Лаеш муниципаль районы, Лаеш шәһәре адресы буенча урнашкан 16:24:170109:55 кадастр номерлы җир участогы территориясенең межалау проектына кагылышлы тәкъдимнәр һәм искәрмәләр ачык тыңлауларда катнашучылар җыелышлары барышында язма яки телдән формада бирелә ала.

Тәкъдимнәр һәм искәрмәләр кыска формада, ачык итеп әйтелгән булырга тиеш.

Ачык тыңлауларда катнашучылар үзләрен таныту максатыннан үзләре турында мәгълүмат тәкъдим итәләр:

физик затлар өчен: фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), туу датасы, яшәү (теркәлү) адресы;

юридик затлар өчен: атамасы, төп дәүләт теркәү номеры (ОГРН), урнашкан урыны һәм адресы.

Бу мәгълүматларга аларныраслый торган документлар кушымта итеп бирелә.

Тиешле капиталь төзелеш объектларының һәм (яисә) әлеге капиталь төзелеш объектларының өлеше булган биналарның (помещениеләрнең) хокук ияләре булган ачык тыңлауларда катнашучылар, шулай ук Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрыннан (ЕГРН) әлеге җир участоклары, капиталь төзелеш объектлары, биналар

турында мәгълүматны һәм капиталь төзелеш объектларына, аларның өлеше булган биналар өчен хокукларын билгели торган яки раслый торган башка документларны тәкъдим итәләр.

Тәкъдимнәр яки искәрмәләр керткәндә, ачык тыңлауларда катнашучылар «Шәхси мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль законга ярашлы рәвештә, ачык тыңлауларны оештыручыга үзләренең шәхси мәгълүматларын эшкәртүгә берсүзсез ризалык бирәләр.

3. Әлеге хәбәр итү (оповещение) «Камская новь» («Кама ягы») район газетасында, Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (веб-адресы: http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләр порталында Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында (веб-адресы: https://laishevo.tatarstan.ru/publichnoe-obsuzhdenie-5676969.htm) бастырып чыгарылырга (халыкка җиткерелергә), шулай ук Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Лаеш шәһәре территориясендә урнашкан мәгълүмат стендларына урнаштырылырга тиеш.

**Җитәкче** **В.А. Арефьев**